Зәй муниципаль районы
Советының
«09» июль 2021 ел
69 номерлы карарына
1 кушымта

**Зәй муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә класслы чиннар бирү тәртибе турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

1. Әлеге нигезләмә белән, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын (алга таба - муниципаль хезмәт вазыйфалары) башкаручы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә (алга таба - муниципаль хезмәткәрләр) класслы чиннар бирү тәртибе, шулай ук муниципаль хезмәткәрләрнең белемнәрен, күнекмәләрен һәм сәләтен (һөнәри дәрәҗәсен) бәяләү тәртибе билгеләнә.

2. Класслы чиннар, алдагы классчы чинда билгеләнгән вакытны исәпкә алып, муниципаль хезмәт вазыйфалары төркеме чикләрендә муниципаль хезмәт вазыйфасы нигезендә, муниципаль хезмәткәрләргә эзлекле рәвештә бирелә.

3. Классчы чин беренчесе яки чираттагысы булырга мөмкин.

4. Муниципаль хезмәт вазыйфасына беренче тапкыр билгеләнгән муниципаль хезмәткәрләргә 3 нче классчы класс чины бирелә.

5. Федераль дәүләт граждан хезмәте классчы чины, дипломатик рангы, хәрби яисә махсус исеме, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең яисә Россия Федерациясенең башка субъектының классчы чины, муниципаль хезмәтнең квалификация разряды булган граждан муниципаль хезмәткә кергәндә, беренче классчы чин аңа муниципаль хезмәт вазыйфалары төркеме чикләрендә биләгән вазыйфасы нигезендә бирелә.

6. Беренче классчы чин муниципаль хезмәткәргә сынауны уңышлы тәмамланганнан соң бирелә, ә сынау билгеләнмәгән булса, муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгәннән соң өч айдан да иртәрәк булмаган вакытта бирелә.

7. 2 һәм 3 классчы муниципаль хезмәт секретаре һәм референтының классчы чиннарда булуның минималь срогы бер ел, 2 һәм 3 классчы муниципаль хезмәт киңәшчесе һәм муниципаль киңәшченеке - ике ел, 2 һәм 3 классчы гамәлдәге муниципаль киңәшченеке бер ел тәшкил итә. 1 классчы секретарь, референт, муниципаль хезмәт киңәшчесе, муниципаль киңәшче һәм 1 классчы гамәлдәге муниципаль киңәшченең класс чиннарында булу вакытлары билгеләнми. Күрсәтелгән муниципаль хезмәткәрләрнең классчы чиннарын арттыру аларны тиешле төркем муниципаль хезмәтенең югарыдагы вазыйфаларына күчергәндә мөмкин.

8. Бирелгән класслы чиннарда булу вакыты алар бирелгән көннән исәпләнә.

9. Класслы чин бирү көне дип класслы чин бирү турында карар кабул ителгән көн санала. Квалификация имтиханы нәтиҗәләре буенча класслы чин бирелгән очракта, класслы чин бирү көне дип муниципаль хезмәткәрләрнең квалификация имтиханын тапшыру көне санала.

10. Чираттагы класслы чин муниципаль хезмәткәргә муниципаль хезмәт узу өчен билгеләнгән срок тәмамланганнан соң, муниципаль хезмәткәр үзенең хезмәт бурычларын тиешенчә үтәгәндә һәм муниципаль хезмәткәргә бирелгән класслы чинга караганда тигез яисә югарырак дәрәҗәдәге муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгән очракта бирелә.

11. Чираттагы класс чины дисциплинар җаваплылыкка тартылган муниципаль хезмәткәрләргә, шулай ук хезмәт тикшерүе уздырыла торган яисә җинаять эше кузгатылган муниципаль хезмәткәрләргә бирелми.

12. Муниципаль хезмәткәрне вазыйфаларның элекке төркеме чикләрендә муниципаль хезмәтнең югарырак вазыйфасына билгеләгәндә аңа, әлеге нигезләмәнең 7 пунктында билгеләнгән элекке класслы чинда булу срогы тәмамланса, чираттагы класслы чин бирелергә мөмкин.

13. Муниципаль хезмәткәрне элек башкарганнан югарырак муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары төркеменә керә торган муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләп куйганда, күрсәтелгән хезмәткәргә 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 9 статьясы нигезендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының әлеге төркеме өчен беренче булган класслы чин бирелә, әгәр дә бу класслы чин муниципаль хезмәткәр ия булган класслы чиннан югары булса.

14. Муниципаль хезмәт вазыйфаларын билгеле бер срокка башкаручы муниципаль хезмәткәрләргә, муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары төркеменә караган муниципаль хезмәткәрләрдән тыш, класслы чиннар квалификация имтиханы нәтиҗәләре буенча бирелә.

15. Муниципаль хезмәткәрләргә класслы чиннар Зәй муниципаль районы башлыгы тарафыннан муниципаль хезмәткәрнең турыдан-туры җитәкчесе тәкъдиме буенча бирелә.

16. Муниципаль хезмәткәргә класслы чин бирү турында карар, әлеге нигезләмәнең 11 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш,

1) квалификация имтиханын үткәрү көненнән соң;

2) квалификация имтиханыннан башка класслы чин бирелгәндә Зәй муниципаль районы башлыгына барлык кирәкле документлар белән класслы чин бирү турында күрсәтмә кертелгәннән соң бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.

17. Квалификация имтиханы муниципаль хезмәткәр инициативасы буенча класслы чин бирү турында мәсьәләне хәл иткәндә муниципаль хезмәткәрләргә класслы чин бирү турында язмача гариза бирелгән көннән соң өч айдан да соңга калмыйча үткәрелә.

18. Квалификация имтиханы Зәй муниципаль районының аттестация комиссиясе тарафыннан дәүләт граждан хезмәткәрләре квалификация имтиханын тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә (алга таба - комиссия) үткәрелә.

19. Зәй муниципаль районы Советының кадрлар эше буенча белгече район башлыгының квалификация имтиханын үткәрү турында күрсәтмәсе проектын әзерли, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) квалификация имтиханын үткәрү датасы һәм вакыты;

б) квалификация имтиханын тапшырырга тиешле муниципаль хезмәткәрләр исемлеге;

в) квалификация имтиханын үткәрү өчен кирәкле документлар исемлеге.

20. Муниципаль район башлыгы күрсәтмәсе, квалификация имтиханы уздыруга бер айдан да соңга калмыйча, имтихан бирәчәк муниципаль хезмәткәрләргә танышу өчен (кул куйдырып), Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә билгеләнгән тәртиптә җибәрелә.

21. Квалификация имтиханын үткәрүгә бер айдан да соңга калмыйча муниципаль хезмәткәрнең турыдан-туры җитәкчесе комиссиягә муниципаль хезмәткәрнең белем, күнекмәләре һәм осталыклары (һөнәри дәрәҗәсе) һәм аңа класслы чин бирү мөмкинлеге турында бәяләмә җибәрә (1 нче кушымта).

22. Муниципаль хезмәткәр әлеге нигезләмәнең 21 пунктында күрсәтелгән бәяләмә белән, квалификация имтиханын үткәрүгә ике атнадан да ким булмаган вакыт эчендә танышырга тиеш.

Муниципаль хезмәткәр комиссиягә үзенең әлеге бәяләмәсе белән килешмәве турында гариза бирергә хокуклы.

23. Квалификация имтиханын үткәргәндә комиссия муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи инструкцияләре таләпләре нигезендә муниципаль хезмәткәрләр башкара торган эшнең катлаулылыгы һәм җаваплылыгы, федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына каршы килми торган муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри сыйфатларын бәяләү методларын кулланып, имтихан процедуралары нигезендә муниципаль хезмәтнең биләгән вазыйфасы буенча вазыйфаи бурыч үтәүгә бәйле мәсьәләләр буенча, шәхси әңгәмә һәм тест үткәрүне дә кертеп, муниципаль хезмәткәрләрнең белемен, осталыгын, сәләтен (һөнәри дәрәҗәсен) бәяли.

24. Квалификация имтиханы нәтиҗәләре буенча муниципаль хезмәткәргә карата комиссия тарафыннан түбәндәге карарларның берсе чыгарыла:

а) муниципаль хезмәткәр квалификация имтиханын тапшырды дип танырга һәм аны класслы чин бирү өчен тәкъдим итәргә;

б) муниципаль хезмәткәр квалификация имтиханын тапшырмады дип танырга.

25. Квалификация имтиханы нәтиҗәсе кушымта нигезендә форма буенча төзелгән муниципаль хезмәткәрнең имтихан кәгазенә кертелә. Имтихан кәгазенә утырышта катнашкан рәис, рәис урынбасары, сәркатип һәм комиссия әгъзалары кул куя (2 нче кушымта).

Муниципаль хезмәткәр имза куеп, имтихан кәгазе белән таныша.

Муниципаль хезмәткәрнең имтихан кәгазе һәм аның белем дәрәҗәсе, күнекмәләре һәм осталыклары (профессиональ дәрәҗә) һәм аңа класслы чин

бирү мөмкинлеге турында бәяләмә муниципаль хезмәткәрнең шәхси эшендә саклана.

26. Квалификация имтиханы нәтиҗәләре район башлыгына аны үткәргәннән соң җиде көннән дә соңга калмыйча җибәрелә.

27. Квалификация имтиханы нәтиҗәләре буенча комиссия тәкъдимнәре район башлыгы тарафыннан классны чин бирү турында карар кабул итү өчен нигез булып тора.

28. Муниципаль хезмәткәргә классны чин бирү турында карар район башлыгы карары белән рәсмиләштерелә. Муниципаль хезмәткәргә классны чин бирү турында белешмәләр аның шәхси эшенә һәм хезмәт кенәгәсенә (булган очракта) кертелә.

29. Муниципаль хезмәткәргә классны чин бирелгәннән соң бирелгән классны чин нигезендә аның вазыйфаи окладына өстәмә билгеләнә һәм бирелгән классны чинда муниципаль хезмәт срогы исәпләнә.

30. Квалификация имтиханын тапшырмаган муниципаль хезмәткәр әлеге имтиханнан соң алты айдан да соңга калмыйча кабат квалификация имтиханын үткәрү инициативасы белән чыга ала.

31. Муниципаль хезмәткәр Россия Федерациясе законнары нигезендә квалификация имтиханы нәтиҗәләренә карата шикаять бирергә хокуклы.

Зәй муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә класслы чиннар бирү тәртибе турында нигезләмәгә 1 кушымта

Квалификация имтиханын тапшыруга тәкъдим ителә торган муниципаль хезмәткәрнең белем, күнекмәләре һәм осталыклары дәрәҗәсе турында һәм аңа класслы чин бирү мөмкинлеге турында бәяләмә

1. Фамилиясе, исеме,атасының исеме ______________________________________________

________________________________________________________________________

2. Туган елы, числосы, ае ____________________________________________________

3. Һөнәри белем, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем булу турында белешмәләр:

________________________________________________________________________

(кайчан һәм нинди уку йортын тәмамлаган,

________________________________________________________________________

белгечлеге һәм квалификациясе буенча белем, гыйльми дәрәҗәсе, гыйльми исеме)

4. Һөнәри яктан яңадан әзерлек,квалификация күтәрү яки стажировка турында белешмәләр:

________________________________________________________________________

(яңадан һөнәри әзерлек, квалификация күтәрү

________________________________________________________________________

яки стажировка турында документлар)

5. Квалификация имтиханын тапшыру вакытына башкарган муниципаль хезмәт вазыйфасы һәм әлеге вазифага билгеләнгән дата ______________________________

________________________________________________________________________

6. Муниципаль хезмәт стажы(шул исәптән дәүләт граждан хезмәте стажы)

________________________________________________________________________

7. Гомуми хезмәтстажы ____________________________________________________

8. Муниципаль хезмәтнең класслы чины ________________________________________

(класс чинының исеме һәм аны бирү датасы)

9. Класслы чин бирү мөмкинлеге турында мәсьәлә хәл ителә ____________________

________________________________________________________________________

10. Аларны хәл итүдә муниципаль хезмәткәр катнашкан төп мәсьәләләр (документлар) исемлеге ________________________________________________________

________________________________________________________________________

11. Муниципаль хезмәткәрнең һөнәри, шәхси сыйфатларын һәм һөнәри хезмәт эшчәнлеге нәтиҗәләрен дәлилләнгән бәяләү һәм аңа класслы чин бирү мөмкинлеген бәяләү ____________________________________________________________________

________________________________________________________________________

Муниципаль хезмәткәрнең турыдан-туры житәкчесе
вазыйфасының аталышы __________________________________________

(имза, тулы имза)

"__" ________ 20__ел

Фикерләр белән таныштым ______________________________________________________

(фамилиясе, инициаллары һәм имзасы, танышу датасы)

Зәй муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә класслы чиннар бирү тәртибе турында нигезләмәгә 2 кушымта

**Муниципаль хезмәткәрнең**
**ИМТИХАН КӘГАЗЕ**

1. Фамилиясе, исеме,атасының исеме ____________________
2. Туган елы, числосы,ае ____________________
3. Һөнәри белем, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем булу турында белешмәләр:
____________________
____________________
(кайчан һәм нинди белем бирү оешмасын тәмамлаган, белгечлеге буенча яки әзерлек юнәлеше буенча квалификациясе, гыйльми дәрәҗәсе, гыйльми исеме)
____________________
4. Өстәмә һөнәри белем турында мәгълүмат ____________________
____________________
(өстәмә һөнәри белем бирү нәтиҗәләре буенча квалификация күтәрүне яки аны алуны раслаучы документлар (квалификация күтәрү турында таныклык, яңадан һөнәри әзерлек турында диплом)
5. Квалификация имтиханын үткәрү көненә башкара торган муниципаль хезмәт вазыйфасы һәм әлеге вазифага билгеләнгән көн ____________________
____________________

6. Муниципаль хезмәт стажы ____________________

7. Гомуми хезмәт стажы ____________________
8. Муниципаль хезмәтнең класс чины ____________________
(класс чинының исеме һәм аны бирү датасы)

9. Муниципаль хезмәткәргә сораулар һәм кыскача җаваплар ____________________
____________________
____________________
____________________
10.Комиссия тарафыннан әйтелгән кисәтмә һәм тәкъдимнәр ____________________
____________________
____________________
____________________
11.Муниципаль хезмәткәрләргә әйтелгән тәкъдимнәр ____________________
____________________
12. Квалификация имтиханы нәтиҗәләре буенча муниципаль хезмәткәрнең белемен, күнекмәләрен һәм сәләтен (һөнәри дәрәҗәсен) бәяләү ____________________
____________________
____________________
(муниципаль хезмәткәр квалификация имтиханын тапшырды һәм аны муниципаль хезмәтнең класслы чинын бирү өчен тәкъдим итәргә; муниципаль хезмәткәр квалификация имтиханын тапшырмады дип танырга)
13. Комиссиянең сан составы _____ кешедән тора.
Утырышта комиссия әгъзаларының _______ катнашты.
Тавышлар саны: риза _________, каршы __________.
14. Искәрмәләр ____________________
Комиссия рәисе
Комиссия рәисе урынбасары
Комиссия секретаре
Комиссия әгъзалары
Имтихан үткәрү датасы
____________________

Имтихан кәгазе белән таныштым____________________
(муниципаль хезмәткәрнең имзасы һәм дата)

(муниципаль орган мөһере өчен урын)

Зәй муниципаль районы
Советының
«09» июль 2020 ел
69 номерлы карарына
2 кушымта

**Квалификация имтиханы үткәрмичә муниципаль хезмәтнең классы чиннарын бирү турында тәкъдимнамә әзерләүнең тәртибе**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының муниципаль хезмәткәрләренә квалификация имтиханы үткәрмичә муниципаль хезмәтнең класслы чиннарын бирү турында тәкъдимнамәне әзерләү тәртибе (алга таба - тәртип) 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясы нигезендә эшләнгән. Әлеге тәртип Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын башкаручы муниципаль хезмәткәрләргә (алга таба - муниципаль хезмәткәрләр) квалификация имтиханы үткәрмичә генә класс чиннары бирү өчен документлар әзерләү, тапшыру һәм карауга бәйле мәсьәләләрне җайга сала.

3. Муниципаль хезмәткәрләргә класслы чиннар бирү турында тәкъдимнамә әзерләү җирле үзидарә органының структур бүлекчәсендә гамәлгә ашырыла.

Класслы чиннарн бирү турында тәкъдимнамә Татарстан Республикасының Зәй муниципаль районы башлыгы исеменә җибәрелә (теркәлә).

4. 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексында билгеләнгән таләпләр үтәлеше турында бәяләмә бирү өчен, кергән тәкъдимнамәләр Зәй муниципаль районы Советының кадрлар эше буенча белгеченә җибәрелә.

Уңай бәяләмә алган очракта, кадрлар эше буенча белгеч җиде көн эчендә Зәй муниципаль районы башлыгының муниципаль хезмәткәргә (муниципаль хезмәткәрләргә) класслы чин (класслы чиннар) бирү турында карар проектын әзерли.

Тискәре бәяләмә бирелгән очракта, кадрлар эше буенча белгеч җиде көн эчендә җирле үзидарә органының структур бүлекчәсенә нигезле баш тартуны җибәрә.

5. Класслы чиннар бирүгә бәйле мәсьәләләр буенча шәхси хезмәт бәхәсләре Россия Федерациясе законнары нигезендә карала.

Квалификация имтиханы үткәрмичә муниципаль хезмәтнең класслы чиннарын бирү турында тәкъдимнамә әзерләү тәртибенә кушымта

Зәй муниципаль районы башлыгы

______________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

**Класслы чин бирүгә тәкъдимнамә**

1. Фамилиясе, исеме, а. и. ______________________________________
2. Туу датасы ______________________________________

3. Һөнәри белеме, гыйльми дәрәҗәсе, гыйльми исеме булу турында белешмәләр:
______________________________________

(нинди уку йортын тәмамлаган, белгечлеге һәм белеме буенча квалификациясе)

______________________________________

4. Яңадан һөнәри әзерлек, квалификация күтәрү яки стажировка турында белешмәләр:
______________________________________

______________________________________

(яңадан һөнәри әзерлек, квалификация күтәрү яки стажировка турында документлар)

5. Башкара торган муниципаль хезмәт вазыйфасы ______________________________________
______________________________________
______________________________________

6. Әлеге вазыйфада эш стажы______________________________________

7. Класслы чинының булуы, бирү датасы ______________________________________

8. Классլы чин бирүгә тәкъдим ителүчегә характеристика ______________________________________
______________________________________
______________________________________
______________________________________
______________________________________

9. Класслы чин бирү турында үтенечнамә ______________________________________
______________________________________

(классլы чинның исеме)

______________________ ______________ ______________

(җитәкче вазыйфасының аталышы (имза) (тулы имза)